КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 1 сентябрь г.Казань № 772

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 31 октябрь, 965 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1262 нче; 2019 ел, 6 май, 380 нче; 2019 ел, 11 июль, 565 нче; 2019 ел, 28 август, 714 нче; 2019 ел, 2 ноябрь, 1008 нче; 2019 ел, 30 декабрь, 1278 нче; 2020 ел, 16 апрель, 294 нче; 2020 ел, 21 май, 413 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

III бүлектә:

3.5 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Өлкән тәрбиячеләргә, тәрбиячеләргә, музыка буенча җитәкчеләргә, укытучы-дефектологларга, укытучы-логопедларга, педагог-психологларга, кече тәрбиячеләргә, тәрбиячеләрнең мәктәпкәчә яшьтәге укучылар (тәрбияләнүчеләр) белән турыдан-туры эшләүче ярдәмчеләренә:

гомуми үсеш юнәлешендәге төркемнәрдә (төрле яшьтәге төркемнәрне кертеп):

ике айдан өч яшькә кадәр – 15 бала;

өч яшьтән белем бирү мөнәсәбәтләре туктатылганга кадәр – 20 бала;

гаилә белеме бирү формасындагы төркемнәрдә – 7 бала;

өч яшькә кадәрге һәм өч яшьтән зуррак балалар өчен компенсацияләү юнәлешендәге төркемнәрдә:

сөйләмендә авыр тайпылышлары булган балалар өчен – 6 бала һәм 10 бала шул ук эзлеклелектә;

сөйләмендә фонетик-фонематик тайпылышлары булган өч яшьтән зуррак балалар өчен – 12 бала;

чукрак балалар өчен – яшь төркемнәренең икесе өчен дә 6 бала;

начар ишетүче балалар өчен – 6 бала һәм 8 бала шул ук эзлеклелектә;

сукыр балалар өчен – яшь төркемнәренең икесе өчен дә 6 бала;

начар күрүче балалар, амблиопия, кылый күзле балалар өчен – 6 бала һәм 10 бала шул ук эзлеклелектә;

терәк-хәрәкәт аппараты бозылган балалар өчен – 6 бала һәм 8 бала;

психик үсешендә тоткарлык булган балалар өчен, акыл үсеше җиңел дәрәҗәдә артта калган балалар өчен – 6 бала һәм 10 бала;

өч яшьтән зуррак акыл үсеше уртача, авыр дәрәҗәдә артта калган балалар өчен – 8 бала;

аутистик спектрдагы бозыклыгы булган балалар өчен – яшь төркемнәренең икесе өчен дә 5 бала;

авыр кимчелекләре (физик һәм (яки) психик үсешендә ике яки аннан да күбрәк кимчелекләре) булган балалар өчен – яшь төркемнәренең икесе өчен дә 5 бала;

катнаш юнәлештәге төркемнәрдә:

өч яшькә кадәрге – иң күбе 10 бала, шул исәптән сәламәтлекләренең мөмкинлекләре чикләнгән иң күбе 3 бала;

өч яшьтән өлкәнрәк:

иң күбе 10 бала, шул исәптән иң күбе 3 чукрак бала, яки сукыр бала, яки терәк-хәрәкәт аппараты бозылган бала, яки акыл үсеше уртача, авыр дәрәҗәдә артта калган бала, яки аутистик спектрда тайпылышлары булган бала, яки авыр дефектлы бала;

иң күбе 15 бала, шул исәптән иң күбе 4 начар күрүче һәм (яки) амблиопия һәм (яисә) кылый күзле бала, яки начар ишетүче бала, яки сөйләмендә авыр бозылышлар булган бала, яки акыл үсеше җиңел дәрәҗәдә артта калган бала;

иң күбе 17 бала, шул исәптән иң күбе 5 психик үсешендә тоткарлык булган бала;

өч яшькә кадәрге һәм өч яшьтән зуррак балалар өчен сәламәтләндерү юнәлешендәге төркемнәрдә:

туберкулез интоксикациясе булган балалар өчен – шул ук эзлеклелектә 10 бала һәм 15 бала;

еш авыручы балалар һәм махсус сәламәтләндерү чаралары комплексы кирәк булган башка категорияләрдәге балалар өчен – 10 бала һәм 15 бала шул ук эзлеклелектә.»;

3.6 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

VI бүлекнең 4 нче пунктындагы унберенче абзацына «Мәгарифтәге казанышлары өчен» Татарстан Республикасы күкрәк билгесе» сүзләреннән соң «һәм «Мактаулы остаз» мактау билгесе» сүзләрен өстәргә;

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән кушымтаның «Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Берлегенең, Россия Совет

Федератив Социалистик Республикасының стимуллаштыру характерындагы түләүләрне бирә торган ведомство (тармак) бүләкләре» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Берлегенең, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының стимуллаштыру характерындагы түләүләрне бирә торган ведомство (тармак) бүләкләре | |
| 1. Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы) | |
| 1.1. | Россия Федерациясенең гомуми белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.2. | Россия Федерациясенең башлангыч һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.3. | Россия Федерациясенең урта һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.4. | Россия Федерациясенең югары һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.5. | Россия Федерациясенең фән һәм техника мактаулы хезмәткәре |
| 1.6. | Россия Федерациясенең яшьләр сәясәте өлкәсе мактаулы хезмәткәре |
| 1.7. | Студентларның фәнни-тикшеренү эшен үстерү өчен |
| 1.8. | Россия Федерациясенең мәгариф өлкәсе мактаулы хезмәткәре |
| 1.9. | Россия Федерациясенең балалар һәм яшьләрне тәрбияләү өлкәсе мактаулы хезмәткәре |
| 1.10. | Мәгариф отличнигы |
| 1.11. | Россия Федерациясенең тәрбия бирү һәм мәгариф мактаулы хезмәткәре |
| 1.12. | Россия Федерациясенең фән һәм югары технологияләр мактаулы хезмәткәре |
| 1.13. | Тәрбия бирү һәм мәгариф өлкәсе ветераны |
| 1.14. | Л.С.Выготский медале |
| 1.15. | К.Д.Ушинский медале |
| 1.16. | «Россия Федерациясенең һөнәри-техник белем бирү отличнигы» билгесе |
| 2. СССР һәм РСФСРның Халык мәгарифе министрлыгы, Мәгариф министрлыгы | |
| 2.1. | «СССРның мәгариф отличнигы» значогы; |
| 2.2. | «Халык мәгарифе отличнигы» значогы; |
| 2.3. | «СССРның һөнәри техник белем бирү отличнигы» значогы |
| 2.4. | «РСФСРның һөнәри-техник белем бирү отличнигы» значогы |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

V бүлекнең 4 нче пунктындагы унберенче абзацына «Мәгарифтәге казанышлары өчен» Татарстан Республикасы күкрәк билгесе» сүзләреннән соң «һәм «Мактаулы остаз» мактау билгесе» сүзләрен өстәргә;

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 1 нче кушымтаның «Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Берлегенең, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының ведомство (тармак) бүләкләре» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Берлегенең, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының ведомство (тармак) бүләкләре | |
| 1. Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы) | |
| 1.1. | Россия Федерациясенең гомуми белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.2. | Россия Федерациясенең башлангыч һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.3. | Россия Федерациясенең урта һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.4. | Россия Федерациясенең югары һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.5. | Россия Федерациясенең фән һәм техника мактаулы хезмәткәре |
| 1.6. | Россия Федерациясенең яшьләр сәясәте өлкәсе мактаулы хезмәткәре |
| 1.7. | Студентларның фәнни-тикшеренү эшен үстерү өчен |
| 1.8. | Россия Федерациясенең мәгариф өлкәсе мактаулы хезмәткәре |
| 1.9. | Россия Федерациясенең балалар һәм яшьләрне тәрбияләү өлкәсе мактаулы хезмәткәре |
| 1.10. | Мәгариф отличнигы |
| 1.11. | Россия Федерациясенең тәрбия бирү һәм мәгариф мактаулы хезмәткәре |
| 1.12. | Россия Федерациясенең фән һәм югары технологияләр мактаулы хезмәткәре |
| 1.13. | Тәрбия бирү һәм мәгариф өлкәсе ветераны |
| 1.14. | Л.С.Выготский медале |
| 1.15. | К.Д.Ушинский медале |
| 1.16. | «Россия Федерациясенең һөнәри-техник белем бирү отличнигы» билгесе |
| 2. СССР һәм РСФСРның Халык мәгарифе министрлыгы, Мәгариф министрлыгы | |
| 2.1. | «СССРның мәгариф отличнигы» значогы; |
| 2.2. | «Халык мәгарифе отличнигы» значогы; |
| 2.3. | «СССРның һөнәри техник белем бирү отличнигы» значогы |
| 2.4. | «РСФСРның һөнәри-техник белем бирү отличнигы» значогы |

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы өстәмә белем бирүче мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәдә:

VI бүлекнең 2.3 нче пунктындагы унберенче абзацына «Мәгарифтәге казанышлары өчен» Татарстан Республикасы күкрәк билгесе» сүзләреннән соң «һәм «Мактаулы остаз» мактау билгесе» сүзләрен өстәргә;

VIII бүлекнең 10 нчы пунктындагы өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Чираттагы финанс елына тренер-укытучыларның югары квалификацияле спортчылар әзерләве өчен һәм ярышларда спортчыларның һәм спортчы-инструкторларның алган нәтиҗәләре өчен физик культура һәм спорт өлкәсендә

эшчәнлек алып баручы һөнәри белем бирү оешмасы җитәкчесенә, җитәкче урынбасарларына, баш бухгалтерына стимуллаштыру характерындагы түләүләрне гамәлгә ашыруга чыгымнар күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 25 сентябрь, 853 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы дәүләт физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәнең VIII бүлеге нигезендә исәпләп чыгарыла.»;

әлеге Нигезләмәгә теркәлгән 2 нче кушымтаның «Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Берлегенең, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының ведомство (тармак) бүләкләре» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Берлегенең, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының ведомство (тармак) бүләкләре | |
|---|---|
| 1. Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы) | |
| 1.1. | Россия Федерациясенең гомуми белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.2. | Россия Федерациясенең башлангыч һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.3. | Россия Федерациясенең урта һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.4. | Россия Федерациясенең югары һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.5. | Россия Федерациясенең фән һәм техника мактаулы хезмәткәре |
| 1.6. | Россия Федерациясенең яшьләр сәясәте өлкәсе мактаулы хезмәткәре |
| 1.7. | Студентларның фәнни-тикшеренү эшен үстерү өчен |
| 1.8. | Россия Федерациясенең мәгариф өлкәсе мактаулы хезмәткәре |
| 1.9. | Россия Федерациясенең балалар һәм яшьләрне тәрбияләү өлкәсе мактаулы хезмәткәре |
| 1.10. | Мәгариф отличнигы |
| 1.11. | Россия Федерациясенең тәрбия бирү һәм мәгариф мактаулы хезмәткәре |
| 1.12. | Россия Федерациясенең фән һәм югары технологияләр мактаулы хезмәткәре |
| 1.13. | Тәрбия бирү һәм мәгариф өлкәсе ветераны |
| 1.14. | Л.С.Выготский медале |
| 1.15. | К.Д.Ушинский медале |
| 1.16. | «Россия Федерациясенең һөнәри-техник белем бирү отличнигы» билгесе |
| 2. СССР һәм РСФСРның Халык мәгарифе министрлыгы, Мәгариф министрлыгы | |
| 2.1. | «СССРның мәгариф отличнигы» значогы; |
| 2.2. | «Халык мәгарифе отличнигы» значогы; |
| 2.3. | «СССРның һөнәри техник белем бирү отличнигы» значогы |
| 2.4. | «РСФСРның һөнәри-техник белем бирү отличнигы» значогы |

әлеге карар белән расланган Югары белем бирүнең мәгариф программаларын – бакалавриат программаларын, специалитет программаларын, магистратура программаларын тормышка ашыру буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыра торган югары белем бирүче дәүләт мәгариф оешмалары һәм Татарстан Республикасының өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә теркәлгән кушымтаның «Россия Федерациясенең, Совет Социалистик Республикалар Берлегенең, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының ведомство бүләкләре» бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының, Совет Социалистик Республикалар Берлегенең, Россия Совет Федератив Социалистик Республикасының ведомство (тармак) бүләкләре | |
| 1. Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы (Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгы) | |
| 1.1. | Россия Федерациясенең гомуми белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.2. | Россия Федерациясенең башлангыч һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.3. | Россия Федерациясенең урта һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.4. | Россия Федерациясенең югары һөнәри белем бирү мактаулы хезмәткәре |
| 1.5. | Россия Федерациясенең фән һәм техника мактаулы хезмәткәре |
| 1.6. | Россия Федерациясенең яшьләр сәясәте өлкәсе мактаулы хезмәткәре |
| 1.7. | Студентларның фәнни-тикшеренү эшен үстерү өчен |
| 1.8. | Россия Федерациясенең мәгариф өлкәсе мактаулы хезмәткәре |
| 1.9. | Россия Федерациясенең балалар һәм яшьләрне тәрбияләү өлкәсе мактаулы хезмәткәре |
| 1.10. | Мәгариф отличнигы |
| 1.11. | Россия Федерациясенең тәрбия бирү һәм мәгариф мактаулы хезмәткәре |
| 1.12. | Россия Федерациясенең фән һәм югары технологияләр мактаулы хезмәткәре |
| 1.13. | Тәрбия бирү һәм мәгариф өлкәсе ветераны |
| 1.14. | Л.С.Выготский медале |
| 1.15. | К.Д.Ушинский медале |
| 1.16. | «Россия Федерациясенең һөнәри-техник белем бирү отличнигы» билгесе |
| 2. СССР һәм РСФСРның Халык мәгарифе министрлыгы, Мәгариф министрлыгы | |
| 2.1. | «СССРның мәгариф отличнигы» значогы; |
| 2.2. | «Халык мәгарифе отличнигы» значогы; |
| 2.3. | «СССРның һөнәри техник белем бирү отличнигы» значогы |
| 2.4. | «РСФСРның һөнәри-техник белем бирү отличнигы» значогы |

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин